**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 48-10 «26» август 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында
(24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41, 16.06.2020 №179-43, 16.04.2021 №36-8, 25.06.2021 №41-9 карарлар редакциясендә*)*

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 23 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2021 елның 19 июлендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41, 16.06.2020 №179-43, 16.04.2021 №36-8, 25.06.2021 №41-9 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

а) Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Нефтьчеләр урамы, 48 нче йорт адресы буенча урнашкан 2334,0 кв. м мәйданлы җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны, Р1 рекреацион-ландшафт территорияләре зонасыннан эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге Д1 зонасына үзгәртергә;

б) Генераль план нигезендә Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләренә кертелгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар һәм авыл хуҗалыгы территорияләре өчен шәхси торак йортлар төзү, С-3 махсус билгеләнештәге транспорт, ТР-1 транспорт объектлары территориаль зоналарын билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай шәһәр Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М.З. Шәйдуллин